**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 22 декабрендәге 4620 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә 2025/2026 уку елында «Ихлас» инклюзив инновацион остазлык проектын оештыруга һәм уздыруга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктның икенче һәм дүртенче абзацлары, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен гамәлгә кертә торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 30 декабрендәге 3985 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә 2025/2026 уку елында «Ихлас» инклюзив инновацион остазлык проектын оештыруга һәм уздыруга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе турында нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов) 2025/2026 уку елында «Ихлас» инклюзив инновацион остазлык проектын оештыруга һәм уздыруга чыгымнарны Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең 2025 һәм 2026 елларга бюджет исемлеге

чикләрендә 0709 бүлеге, 02 602 43600 «Мәгариф үсешенә юнәлдерелгән чаралар, гомумшәһәр чаралары» максатчан статьясы буенча 3 000,0 мең сум күләмендә гамәлгә ашырырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 22 декабрендәге
4620 номерлы карары белән
расланды

**Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә 2025/2026 уку елында «Ихлас» инклюзив инновацион остазлык проектын оештыруга һәм уздыруга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренә (алга таба – учреждениеләр, гомуми белем бирү учреждениеләре) 2025/2026 уку елында максатлары һәм бурычлары Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 22 декабрендәге 4298 номерлы карары белән билгеләнгән «Ихлас» инклюзив инновацион остазлык проектын оештыруга һәм уздыруга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр (алга таба – максатчан субсидия, субсидия) бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен гамәлгә кертә.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

- гомуми белем бирү учреждениесе – Казан шәһәре территориясендә урнашкан муниципаль бюджет яки автоном гомуми белем бирү учреждениесе;

- субсидия – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы гомуми белем бирү учреждениеләренә бирелә торган акча чаралары;

- субсидия алучы – гомуми белем бирү учреждениеләре – «Ихлас» остазлар проектында катнашучылар. Аларның исемлеге Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 1 августындагы 2522 номерлы карары белән расланган.

1.3. Бурычлар:

- Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендә инклюзив белем бирүнең булган практикаларын туплау һәм анализлау;

- педагоглар берләшмәсе игътибарын инвалид балаларны һәм сәламәтлеге

ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны гомуми белем бирү системасына җәлеп итүгә юнәлдерү;

- җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары игътибарын белем бирүдә инклюзив алымны үстерүгә җәлеп итү;

- педагоглар тарафыннан, заманча технологияләр һәм инструментлар кулланып, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларга белем бирүнең яңа методикаларын үзләштерү;

- муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре арасында остазлык өлкәсендә тәҗрибә алмашу, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле һәм инвалидлыгы булган укучыларга белем һәм тәрбия бирү тәҗрибәсе белән уртаклашу;

- яңа методик ярдәмлекләр булдыру, уку-укыту процессында яңа технологияләрне гамәлгә кертү;

- аутистик спектры бозылган һәм менталь тайпылышлары булган балаларга белем бирүнең сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү.

1.4. Субсидия алучыларга субсидия бирү максатлары – гомуми белем бирү учреждениеләрендә сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар (аутистик спектры бозылган һәм менталь тайпылышлары булган укучылар) белән эшләүче педагогларның һөнәри компетенцияләрен үстерү, инклюзив белем бирү өлкәсендә эшчәнлекне оештыруның нәтиҗәле тәҗрибәсен популярлаштыру, шулай ук уңай педагогик тәҗрибә белән уртаклашу, аутистик спектры бозылган һәм менталь тайпылышлары булган балаларга инклюзив мохиттә ярдәм күрсәтү.

Максатчан субсидияләр, муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләргә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган буларак, Казан шәһәре Башкарма комитеты исеменнән эш йөртүче структур бүлекчә – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе тарафыннан бирелә. Аңа, бюджет акчаларын алучы буларак, 2025 һәм 2026 елларга максатчан субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелә.

1.5. Субсидия максатчан билгеләнешкә ия һәм аны алучы тарафыннан әлеге Нигезләмә белән каралмаган максатларда файдаланыла алмый.

1.6. Субсидия бирү 2025 һәм 2026 елларга Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең бюджет исемлеге чикләрендә гамәлгә ашырыла.

1.7. Субсидия бирү өчен бүлеп бирелгән бюджет акчаларын төп бүлүче – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе (алга таба – Вәкаләтле орган).

## II. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Максатчан субсидия алуга дәгъва кылучы учреждение Мәгариф идарәсенең электрон почта адресына (info@kazanobr.ru) әлеге Нигезләмәгә кушымтада билгеләнгән форма буенча гариза җибәрә, аңа максатчан субсидия алу өчен тапшырыла торган документлар исемлеге буенча тапшырылган документлар исемлеген теркәп бирә. Исемлек түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- субсидия суммасын исәпләү-нигезләүне, шул исәптән тиешле эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә), чаралар үткәрүгә беренчел сметаны дә кертеп, бюджет акчаларын әлеге Нигезләмәнең 1.1 пункты белән билгеләнгән максатларга бирү кирәклеген нигезләүне үз эченә алган аңлатма язуы;

- субсидия бирү максаты чаралар, шул исәптән конференцияләр, симпозиумнар, күргәзмәләр үткәрү булган очракта, чаралар программасы;

- учреждениенең әлеге Нигезләмәнең 2.3 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документлар.

2.2. Мәгариф идарәсе:

а) гаризаны килеп ирешкән көнне терки;

б) әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларның тулылыгын, алардагы мәгълүматның җитәрлек булуын һәм дөреслеген карап тикшерә;

в) гаризаны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә субсидия бирү турында яки субсидия бирүне кире кагу турында карар кабул итә.

Кирәкле барлык документлар тапшырылмаган яки алар тиешенчә тутырылмаган очракта, Мәгариф идарәсе, карап тикшерү вакыты тәмамланырга кимендә ике эш көне кала, ачыкланган җитешсезлекләрне төзәтү өчен күрсәтелгән документларны кире кайтара.

Хәбәрнамә учреждениегә Мәгариф идарәсенә электрон документ рәвешендә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә яки Мәгариф идарәсенә язма рәвештә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.

Учреждение тарафыннан җитешсезлекләрне бетерү вакыты – хәбәрнамә Мәгариф идарәсендә теркәлгән көннән алып биш эш көненнән дә артык түгел.

2.3. Учреждениегә субсидия бирүне кире кагу өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

- учреждение тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.1 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән

документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 1.4 пункты белән билгеләнгән максатларга туры килмәве;

- учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

- агымдагы финанс елында Мәгариф идарәсенең бюджет исемлегендә каралган бюджет йөкләмәләре лимитларын максатчан субсидияләр бирүгә тулысынча бүлү.

Субсидия бирүне кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, учреждениегә мондый карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә, субсидия бирүне кире кагу сәбәбен күрсәтеп, кире кагу турында хәбәрнамә җибәрелә.

Кире кагу турында хәбәрнамә учреждениегә Мәгариф идарәсенә электрон документ рәвешендә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә яки Мәгариф идарәсенә язма рәвештә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.

Кире кагу өчен нигез булып торган җитешсезлекләр бетерелгән очракта, учреждение документларны кабат җибәрергә хокуклы.

Учреждение тарафыннан документларның тулы җыелмасы тапшырылган һәм тапшырылган документлар әлеге Нигезләмәнең 1.4 пункты белән билгеләнгән максатларга туры килгән очракта, шулай ук максатчан субсидия бирүне кире кагу өчен әлеге Нигезләмәнең 2.3 пункты белән каралган нигезләр булмаса, Мәгариф идарәсе әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән вакыт эчендә субсидия бирү мөмкинлеге турындагы бәяләмә рәвешендә учреждениегә максатчан субсидия бирү турында карар кабул итә.

2.4. Бирелә торган субсидия күләме, учреждениенең әлеге Нигезләмәнең 2.1 пункты нигезендә тапшырыла торган гаризада һәм аңлатма язуында күрсәтелгән ихтыяҗын исәпкә алып, Мәгариф идарәсе тарафыннан түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З1 + З2 + З3 +... + Зn, \text{ биредә:}$$

С – 2025/2026 уку елында «Ихлас» инклюзив инновацион остазлык проектын оештыруга һәм уздыруга субсидия суммасы;

З1, З2, З3, .., Зn – 2025/2026 уку елында «Ихлас» инклюзив инновацион остазлык проектын оештыру һәм уздыру белән бәйле чыгымнар.

Субсидия күләме Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларын алучы буларак максатчан субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре

лимитлары җиткерелгән Мәгариф идарәсенә 2025 һәм 2026 елларга билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә билгеләнә.

2.5. Субсидия бирү мөмкинлеге турындагы бәяләмә рәвешендә учреждениегә максатчан субсидия бирү турында карар кабул ителгән вакыттан алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, Мәгариф идарәсе субсидия алучыга Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе тарафыннан раслана торган типлаштырылган форма буенча килешү (алга таба – Килешү) юллый, анда шул исәптән түбәндәгеләр күздә тотыла:

а) әгәр субсидияләр тиешле программаларны, проектларны гамәлгә ашыру максатыннан бирелсә, илкүләм проект (программа), шул исәптән тиешле илкүләм проект (программа) составына керүче муниципаль проект яки муниципаль программа максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итүче муниципаль проект исемен күрсәтеп, субсидия бирү максатлары;

б) субсидия бирү нәтиҗәләренең конкрет, үлчәп була торган һәм әлеге Нигезләмәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән муниципаль проектлар, муниципаль программалар нәтиҗәләренә туры килә торган (муниципаль программаларда мондый программаларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре булган очракта) (әгәр субсидия мондый программаларны, проектларны гамәлгә ашыру максатыннан бирелсә) күрсәткечләре һәм, тиешле программалар, проектлар нәтиҗәләренә ирешү барышында алырга планлаштырыла торган матди һәм матди булмаган объектлар һәм (яки) хезмәтләр өлешендәге күрсәткечләрне дә кертеп (мондый детальләштерү мөмкинлеге булганда), субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр;

в) субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планы;

г) субсидия күләме;

д) субсидияне күчерү вакыты (графигы);

е) хисап бирү вакыты;

ж) учреждение тарафыннан Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлмәгән очракта, субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм вакыты;

з) Килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән бюджет акчаларын алучы буларак Мәгариф идарәсенә алдан җиткерелгән субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары киметелгән очракта;

и) Мәгариф идарәсе карары буенча берьяклы тәртиптә килешүне вакытыннан алда туктату өчен нигезләр, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле

рәвештә:

- учреждениене үзгәртеп оештыру (кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш) яки ябу;

- учреждение тарафыннан субсидия бирүнең хокукый акт һәм (яки) Килешү белән билгеләнгән максатларын һәм шартларын бозу;

и) учреждение тарафыннан Килешүне берьяклы тәртиптә өзүне тыю.

2.6. Субсидия алучы Килешүне алган көннән соң килә торган өч эш көне эчендә аны имзалый һәм имзаланган вариантны электрон документ рәвешендә Мәгариф идарәсенә җибәрә.

2.7. Килешү ике як тарафыннан да имзаланганнан соң төзелгән дип санала.

2.8. Килешүгә үзгәрешләр кертелгән яки Килешү өзелгән очракта, яклар язма рәвештә өстәмә килешү төзиләр.

2.9. Субсидия алучы тарафыннан имзаланган Килешү әлеге Нигезләмәнең 2.6 пункты белән билгеләнгән вакыт эчендә тапшырылмаган очракта, субсидия алучы Килешү төзүдән читләшкән дип санала һәм субсидия алу хокукыннан мәхрүм ителә.

2.10. Максатчан субсидия субсидия алу һәм аңардан файдалану операцияләрен исәпкә алу өчен Федераль казначылык органында учреждение тарафыннан ачылган шәхси счетка субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып 10 эш көне эчендә күчерелә.

2.11. 2025/2026 уку елында «Ихлас» инклюзив инновацион остазлык проектын гамәлгә ашыру субсидия бирү нәтиҗәсе булып тора.

2025/2026 уку елында «Ихлас» инклюзив инновацион остазлык проектын гамәлгә ашыруга субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен бер белем бирү учреждениесенә 2025 һәм 2026 елларга 36 сәгатьтән дә ким булмаган күләмдә «проектны тәэмин итү буенча мәгълүмат-консультация хезмәтләре комплексы» күрсәткече билгеләнә.

2.12. Килешү төзү яки субсидия бирү турында карар кабул итү планлаштырылган айдан алда килә торган айның беренче көненә учреждение түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

- учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау;

- учреждениене үзгәртеп оештыру яки ябу буенча чараларны гамәлгә ашыруга, аварияне (гадәттән тыш хәлләрне) кисәтүгә, авария (гадәттән тыш хәлләр) килеп чыкканда аның нәтиҗәләрен бетерү һәм торгызу эшләрен

башкаруга субсидия бирү очракларыннан тыш, учреждениенең Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча түләү вакыты узган бурычы булмау;

- учреждениенең законлы көченә кергән суд актлары, башкарма документлар, шулай ук федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенә караган югары башкарма органының норматив хокукый актлары, Казан шәһәре Башкарма комитетының муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән башка очракларда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча түләү вакыты узган бурычы булмау;

- учреждение инновацион мәйданчыклар – Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 1 августындагы 2522 номерлы карары белән расланган «Ихлас» инклюзив инновацион остазлык проектында катнашучы мәгариф оешмалары исемлегенә керә.

## III. Хисап бирүгә таләпләр

3.1. Учреждение әлеге Нигезләмәнең 3.2 пункты белән билгеләнгән вакыт эчендә Мәгариф идарәсенә бирелгән субсидиядән файдалану турында, шул исәптән учреждение тарафыннан тотылган чыгымнар турында һәм максатчан күрсәткечләргә ирешү турында Килешү белән билгеләнгән формалар буенча хисап (алга таба – хисап) тапшырырга тиеш.

3.2. Учреждение Мәгариф идарәсенә хисапны 2026 елның 15 сентябренә кадәр тапшыра.

3.3. Бирелгән максатчан субсидиядән файдалану турында хисап бирү формасы, тәртибе һәм вакыты Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе тарафыннан раслана һәм, субсидия бирү максатын исәпкә алып, Килешү белән билгеләнә.

## IV. Субсидия бирү максатларының, шартларының һәм тәртибенең үтәлешен контрольдә тоту һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылык

4.1. Максатчан субсидияләрнең 2026 елның 15 сентябренә файдаланылмый калган өлеше Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына күчерелергә тиеш.

4.2. 2026 елның 30 сентябренә кадәр Мәгариф идарәсе Казан шәһәре Башкарма комитетынең Финанс идарәсенә, Килешү белән билгеләнгән вакытта кабул ителгән чыгым йөкләмәләре булмау сәбәпле, максатчан субсидияләр акчаларының хисап чорында файдаланылмаган һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кайтарылырга тиешле калган өлеше турында мәгълүмат җибәрә.

4.3. Максатчан субсидия биргәндә билгеләнгән максатларга ирешү өчен агымдагы финанс елында финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан субсидияләр булган учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан кергән керемнәрдән файдалану турындагы карар, Мәгариф идарәсе белән килештереп, учреждение тарафыннан кабул ителә.

Агымдагы финанс елында максатчан субсидияләр финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан кергән акчалардан файдалану турында карар кабул итү өчен учреждениеләр Мәгариф идарәсенә учреждениеләрнең агымдагы финанс елының 1 гыйнварына учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан алынган акча финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган үтәлмәгән йөкләмәләре булуы турында мәгълүматны, шулай ук учреждениенең әлеге йөкләмәләре (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуын һәм күләмен раслый торган документларны (документларның күчермәләрен), акча килеп ирешкәннән соң, өч эш көне эчендә тапшыра.

Мәгариф идарәсе, әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат килеп ирешкәннән соң, 10 эш көне эчендә килештерү/килештермәү турында карар кабул итә.

4.4. Россия Федерациясе законнары нигезендә Мәгариф идарәсе субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәлешен тикшерә.

Муниципаль финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерү үткәрәләр.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча субсидия бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен бәяләү мөмкин булмаса, урынга чыгып тикшерү үткәрелә. Субсидия алучы контроль өчен керү мөмкинлеген тәэмин итәргә, шулай ук күчмә тикшерү барышында субсидия бирү белән бәйле соралган документларны тапшырырга тиеш.

4.5. Тикшерүләр нәтиҗәсе буенча учреждениенең максатчан субсидия биргәндә билгеләнгән максатларны һәм шартларны үтәмәве ачыкланган очракта,

учреждение максатчан субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән очракта, шулай ук учреждение әлеге Нигезләмәнең III бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә максатчан субсидиядән файдалану турында хисаплар тапшырмаган очракта, максатчан субсидия Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

4.6. Максатчан субсидияне яки аның бер өлешен кире кайтару турында таләп аны алган көннән башлап 30 (утыз) календарь көн эчендә учреждение тарафыннан үтәлергә тиеш.

Субсидияне кире кайтару турындагы таләп билгеләнгән вакыт эчендә үтәлмәгән очракта, Мәгариф идарәсе аны Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә түләтүне тәэмин итә.

4.7. Субсидия акчаларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдаланган өчен, шулай ук субсидия алу өчен тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә субсидия алучы учреждение җитәкчесенә йөкләнә.

Казан шәһәре Башкарма комитетының
Мәгариф идарәсе карамагындагы
муниципаль гомуми белем бирү
учреждениеләренә 2025/2026 уку елында
«Ихлас» инклюзив инновацион остазлык
проектын оештыруга һәм уздыруга
субсидияләр бирү күләмен һәм
шартларын билгеләү тәртибе турында
нигезләмәгә кушымта
(Форма)

Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан 2025/2026 уку елында «Ихлас» инклюзив инновацион остазлык проектын оештыруга һәм уздыруга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидия алуга
гариза

Субсидия бирү максаты: ________________________________________

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүче | |
| 2 | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) | |
| 3 | Төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) | |
| 4 | Юридик адресы | |
| 5 | Телефон номеры | |
| 6 | Электрон почта адресы | |
| 7 | Җитәкче | |
| 8 | Субсидия күләме, сумнарда | |
| 9 | Субсидия күчерү өчен реквизитлар | |
| 10 | Субсидия алу мөмкинлеген бирә торган дөрес булмаган белешмәләр тапшырган өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылык каралган булуы турында миңа әлеге гариза белән хәбәр ителде<br>_________________<br>(имза) | |
| 11 | Учреждениенең Нигезләмәнең 2.12 пункты белән каралган таләпләргә туры килүен раслыйм | |
| 12 | Субсидия бирү шартлары белән таныштым һәм Тәртип нигезендә исемлек буенча кирәкле документларны тапшырам | |

Директор ____________________________________________
(имза, фамилия һәм инициаллар)

Гариза бирү датасы: 20____ елның «_______» ________________